РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 18 » 09 2024 ел № 894

2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында»гы 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында"гы 25.06.2013 ел, № 52-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау турында"гы 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "2025 елга күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау региональ программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын төзәтү турында"гы 16.07.2024 ел, № 01-09-12856 хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. 2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кушымтада бирелә торган кыска сроклы планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында»гы 12.12.2023 елның № 2056 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

Н.В. Топорова
8(85593) 2-42-07

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының
«___»_________20__ ел №_______
карарына кушымта

2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы

## I. Гомуми нигезләмәләр

2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның әлеге кыска сроклы планы (алга таба – кыска сроклы план, Региональ программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында»гы 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында»гы 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауның региональ программасын раслау турында"гы 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы " муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтү һәм (яисә) эш төрләрен төгәлләштерү, дәүләт ярдәме, капиталь ремонт ясауга муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында эшләнде.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска сроклы планның төп максатлары булып:

- Татарстан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын арттыру;
- гражданнарның яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру;
- дәүләт ярдәме, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга муниципаль ярдәм.

Кыска сроклы планның төп бурычлары булып:

- халык белән актив агитация-аңлату эше алып бару;

кыска вакытлы план үтәүчеләрне сайлап алуның үтә күренмәле һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;

- озакка чыдам материаллар һәм ресурсларны саклый торган технологияләр кулланып капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрдән һәм комплекслылыктан файдалану.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру вакыты: 2023-2025 еллар.

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру 1022 гражданга гомуми мәйданы 25074,57 кв. метр булган 20 күпфатирлы йортта имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге кыска сроклы планны үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы буенча кыска сроклы планга 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

## III. 2023-2025 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | 2023 | 2024 | 2025 |
| Түбә ремонты | кв. м | 924,50 | - | - | 924,50 |
| Подвалны ремонтлау | кв. м | - | - | - | - |
| Фасадны ремонтлау | кв. м | - | - | - | - |
| Фасадны җылыту | кв.м. | 15 182,67 | 8 210,77 | 3284,00 | 3687,90 |
| Фундаментны ремонтлау | кв.м | | | | |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән: | | | | | |
| электр белән тәэмин итү | пог. м | 1 338,00 | - | 678,00 | 660,00 |
| салкын су белән тәэмин итү | пог. м | 777,00 | - | 293,50 | 483,50 |
| Су үткәрү | пог. м | 714,80 | - | 247,80 | 467,00 |

Кыска сроклы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры әлеге кыска сроклы планга 2 нче кушымтада китерелгән.

## IV. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска сроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты, торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш кооперативлары (алга таба – ТСЖ, ТК, ТТК) яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары йә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре акчалары тора.

Кыска сроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме 88 372 281,31 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- Татарстан Татарстан Республикасы бюджетыннан – 16.256.873, 94 мең сум;

- Ютазы муниципаль районы бюджетыннан – 13 965 000,00 мең сум;
- күпфатирлы йортта торак милекчеләре - 58 150 407,37 мең сум.

2023-2025 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга финанс чаралары күләме.

| Хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге | Сумма, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | 2023 | 2024 | 2025 |
| Түбә ремонты | 3 457 863,40 | - | - | 3 457 863,40 |
| Фасадны җылыту | 74 158 591,98 | 31 499 804,85 | 21 982 042,13 | 20 676 745,00 |
| Фундаментны ремонтлау | - | - | - | - |
| Йорт эчендәге инженер системалары | 6 352 325,00 | - | 2 215 550,00 | 4 136 775,00 |
| Проект документациясен эшләү | 3 037 022,85 | 1 127 393,77 | 869 530,36 | 1 040 098,72 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 1 366 478,08 | 530 027,25 | 390 083,08 | 446 367,75 |
| Барлыгы | **88 372 281,31** | **33 157 225,87** | **25 457 205,57** | **29 757 849,87** |

Капиталь ремонт үткәрү бәясе күрсәтелгән күпфатирлы йортлар исемлеге кыска сроклы планга 3 нче кушымтада китерелгән.

V. Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе

Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе 2023-2025 елларга күпфатирлы йортлардагы биналарның гомуми мәйданының 1 кв.метрына исәпләгәндә 14 мең сум тәшкил итә.

Шул ук вакытта әлеге кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүнең (эшнең) иң чик бәясе күләме эш төрләре буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба - Министрлык) боерыгы белән раслана.

Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясеннән артып китү, шулай ук кыска сроклы планда каралмаган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өчен түләү күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең капиталь ремонтка кертемнең минималь күләменнән артыграк күләмендә капиталь ремонтка кертем рәвешендә түләнә торган акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясеннән артып киткән өчен кыска сроклы планны гамәлгә ашыруга каралган җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләү рөхсәт ителә.

## VI. Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге кыска сроклы планны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, ТМШ, ТК, ТТК, идарәче оешмалар (алга таба - ИО), биналар милекчеләре, подряд оешмалары (алга таба - кыска сроклы планны үтәүчеләр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты:**

- күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, өч елга төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планнарын төзи һәм министрлыкка җибәрә;
- министрлыкка норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм муниципаль берәмлекнең финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәвен раслый торган башка документларны тапшыра;
- капиталь ремонт эшләрен торак законнары нигезендә кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә финанслауга җирле бюджет акчаларын күчерә;
- региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләрнең техник заказчысы функцияләрен башкара;
- башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын килештерә, моңа күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау чыгымнарының расланган сметасында каралмаган акчалардан файдалану очраклары керми, шулай ук ул арткан очракта;
- күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан файдаланылуын тикшереп тора;
- тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска сроклы планны (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча белешмәләрне) гамәлгә ашыру максатларында белешмәләр базасын төзи һәм актуаль хәлдә тота;
- министрлыкка һәм кыска сроклы планны башка башкаручыларга дәүләт корпорациясенә - торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фондына хисаплар формалаштыру өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр тапшыра.

**ТМШ, ТТК, ТК, ИО:**

- тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә дефектлы ведомостьларны килештерәләр;
- проект документациясен килештерүне тәэмин итәләр;
- милекчеләргә капиталь ремонтны башлау срогы, кирәкле исемлек һәм хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары

турында тәкъдимнәр һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тәкъдим итәләр;
- күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышлары оештыралар;
- капиталь ремонт объектларына кертүне гамәлгә ашыралар;
- күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны тикшереп торалар, шулай ук капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә тикшерү актларына һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру актларына имза салу хокукы белән катнашалар;
- күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча дефектлы ведомостьлар, проект-смета һәм башкарма документацияне күпфатирлы йортны һәм аңа кирә торган инженер системаларын аварияссез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия срогыннан ким булмаган килеш саклыйлар;
- төбәк операторы белән шартнамәләр (килешүләр) төзи, алар нигезендә ТМШ, ТТК, ТК, ИО түләү документларын төзи һәм ай саен исәпләүне, төбәк операторы счетына капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләрнең түләүләрен, шулай ук капиталь ремонт өчен кертемнәр һәм пеня түләү буенча бурычларны түләтү чараларын тәэмин итә.

**Биналарның милекчеләре:**

- тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә дефектлы ведомостьларны килештерәләр;
- күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны тикшереп торуда, шулай ук тикшерү актларына һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру актларына имза салу хокукы белән аларны файдалануга кабул итүдә катнашалар.

**Подряд оешмалары:**

- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен кыска сроклы план һәм подряд шартнамәсендә билгеләнгән срокларда башкаруны тәэмин итәләр;
- башкарылган эшләрнең актларын КС-2, КС-3 формалары буенча төзиләр;
- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;
- күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;
- объектны эксплуатациягә кертүне тәэмин итәләр;
- подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

**Техник заказчылар:**

- проект документациясен, шул исәптән сметаларны әзерләү һәм раслауны гамәлгә ашыралар;
- күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

- башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләрнең актларын килештерәләр;

- объектны кабул итүдә катнашалар, капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясе төзиләр, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау эшләрен кабул итү комиссиясе актларын килештерәләр;

- күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

- проект оешмасыннан проект документациясен кабул итәләр;

- күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куелганнан соң 10 көн эчендә шушы күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән проект-смета документациясенең, хезмәт күрсәтү турындагы шартнамәләрнең һәм (яисә) капиталь ремонт) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документлар, финанс документларыннан тыш;

- техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен башкара.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## VII. Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру тәртибе

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру тәртибе Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына 1 нче кушымта

**Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре**

| № т/б | Оешма исеме | Күпфатирлы йортларның гомуми мәйданы, кв.метр | Региональ программаны раслау датасына КФЙда теркәлгән халык саны | КФЙ саны, данә | | | | | Капиталь ремонт бәясе, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | Барлыгы | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | Барлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | 2023 | | | | | | | | | | | | |
| 1 | ТМШ, ТТК, Идарәче компанияләр | 9626,20 | 392 | | | | 6 | 6 | | | | 33 157 225,87 | 33 157 225,87 |
| | 2024 | | | | | | | | | | | | |
| 2 | ТМШ, ТТК, Идарәче компанияләр | 7513,40 | 304,00 | | | | 6 | 6 | | | | 25 457 205,57 | 25 457 205,57 |
| | 2025 | | | | | | | | | | | | |
| 3 | ТМШ, ТТК, Идарәче компанияләр | 7934,97 | 326,00 | | | | 8 | 8 | | | | 29 757 849,87 | 29 757 849,87 |
| | **Барлыгы:** | **25074,57** | **1022,00** | | | | **20** | **20** | | | | **88 372 281,31** | **88 372 281,31** |

2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына 2 нче кушымта

**2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау региональ программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры**

| № т/б | КФЙның адресы | Капиталь ремонтның бәясе - барлыгы | Россия Федерациясе Торак кодексының 166 маддәсенең 1 өлешендә билгеләнгән төрләр: | | | | | | | | | | 2023 елгы КФЙка проект документациясен эшләү | 2024 елгы КФЙка проект документациясен эшләү | 2025 елгы КФЙка проект документациясен эшләү | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Инженерлык системаларын ремонтлау, шул исәптән: | | | | | | Фасадны җылыту | | Тхюәләрне ремонтлау | | | | | |
| | | | Су үткәрү | | ХВС | | электр белән тәэмин итү | | | | | | | | | |
| | | сум | пог. м | сум | пог. м | сум | пог. м | сум | кв.метр | сум | кв. метр | сум | сум | сум | сум | сум |
| 1 | 2 | 3 | | | | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| **2023** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | ш.т.б. Урыссу, Альберт Шамкин ур., 49 йорт | 7 503 721,61 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 1 425,00 | 7 138 677,35 | 0,00 | 0,00 | 247 442,79 | 0,00 | 0,00 | 117 601,47 |
| 2 | Урыссу ш. т. б., Урыссу ур., 22а й. | 12 538 005,07 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 5 010,65 | 11 988 351,68 | 0,00 | 0,00 | 360 235,67 | 0,00 | 0,00 | 189 417,72 |
| 3 | пш.т.б. Урыссу, Тукай ур, 25 йорт | 3 735 672,42 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 558,50 | 3 548 543,16 | 0,00 | 0,00 | 130 877,79 | 0,00 | 0,00 | 56 251,47 |
| 4 | ш.т.б. Урыссу, Жуков ур., 45 йорт | 3 484 415,73 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 336,00 | 3 252 263,97 | 0,00 | 0,00 | 160 375,29 | 0,00 | 0,00 | 71 776,47 |
| 5 | Әбсәләм ав., Советская ур., 56А йорт, | 3 833 199,29 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 555,00 | 3 631 853,70 | 0,00 | 0,00 | 140 191,94 | 0,00 | 0,00 | 61 153,65 |
| 6 | ш.т.б. Урыссу, Пушкин ур., 103 йорт | 2 062 211,75 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 325,62 | 1 940 114,99 | 0,00 | 0,00 | 88 270,29 | 0,00 | 0,00 | 33 826,47 |
| | **Барлыгы:** | **33 157 225,87** | **0,00** | **0,00** | **0,00** | **0,00** | **0,00** | **0,00** | **8 210,77** | **31 499 804,85** | **0,00** | **0,00** | **1 127 393,77** | 0,00 | 0,00 | **530 027,25** |
| **2024** | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ш.т.б. Урыссу, Альберт Шамкин ур., 48 йорт | 2 350 000,00 | 247,80 | 754 400,00 | 293,50 | 611 450,00 | 678,00 | 849 700,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 90 975,00 | 0,00 | 43 475,00 |
| 2 | Урыссу ш. т. б., Урыссу ур., 66 й. | 5 600 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 850,00 | 5 332 400,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 183 600,00 | 0,00 | 84 000,00 |
| 3 | ш.т.б. Урыссу, Пушкин ур., 95 йорт | 4 100 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 610,00 | 3 897 650,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 140 850,00 | 0,00 | 61 500,00 |
| 4 | Алабакүл авылы, Үзәк ур., 1 йорт | 3 707 205,57 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 530,00 | 3 521 942,13 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 129 655,36 | 0,00 | 55 608,08 |
| 5 | Әбсәләм ав., Комсомол ур., 3 й. | 4 850 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 647,00 | 4 615 025,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 162 225,00 | 0,00 | 72 750,00 |
| 6 | Әбсәләм ав., Комсомол ур., 4 й. | 4 850 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 647,00 | 4 615 025,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 162 225,00 | 0,00 | 72 750,00 |
| | **Барлыгы:** | **25 457 205,57** | **247,80** | **754 400,00** | **293,50** | **611 450,00** | **678,00** | **849 700,00** | **3 284,00** | **21 982 042,13** | **0,00** | **0,00** | 0,00 | **869 530,36** | 0,00 | **390 083,08** |
| **2025** | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Урыссу ш. т. б., Урыссу ур., 72 й. | 5 500 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 1 288,90 | 5 236 750,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 180 750,00 | 82 500,00 |
| 2 | Урыссу ш. т. б., Урыссу ур., 24 й. | 4 350 000,00 | 467,00 | 1 378 925,00 | 483,50 | 1 091 975,00 | 660,00 | 1 665 875,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 147 975,00 | 65 250,00 |
| 3 | Урыссу ш. т. б., М. Җәлил ур., 6а й. | 6 700 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 839,00 | 4 913 975,00 | 370,00 | 1 470 575,00 | 0,00 | 0,00 | 214 950,00 | 100 500,00 |
| 4 | Урыссу ш. т. б., Пушкин ур., 99 | 2 750 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 380,00 | 2 606 375,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 102 375,00 | 41 250,00 |
| 5 | Урыссу ш. т. б., Пушкин ур., 109 | 5 230 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 740,00 | 4 978 495,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 173 055,00 | 78 450,00 |
| 6 | Урыссу ш.т.б., Мияссаров ур, 48 | 3 100 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 440,00 | 2 941 150,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 112 350,00 | 46 500,00 |
| 7 | Урыссу ш. т. б., Жуков ур., 17 й. | 807 849,87 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 204,50 | 748 708,40 | 0,00 | 0,00 | 47 023,72 | 12 117,75 |
| 8 | Урыссу ш.т.б., Островский ур., 25 й. | 1 320 000,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 350,00 | 1 238 580,00 | 0,00 | 0,00 | 61 620,00 | 19 800,00 |
| | **Нибары:** | **29 757 849,87** | **467,00** | **1 378 925,00** | **483,50** | **1 091 975,00** | **660,00** | **1 665 875,00** | **3 687,90** | **20 676 745,00** | **924,50** | **3 457 863,40** | **0,00** | **0,00** | **1 040 098,72** | **446 367,75** |
| | **Барлыгы:** | **88 372 281,31** | **714,80** | **2 133 325,00** | **777,00** | **1 703 425,00** | **1 338,00** | **2 515 575,00** | **15 182,67** | **74 158 591,98** | **924,50** | **3 457 863,40** | **1 127 393,77** | **869 530,36** | **1 040 098,72** | **1 366 478,08** |

2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына 3 нче кушымта

**2023-2025 елларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән күпфатирлы йортлар исемлеге**

| № т\б | КФЙның адресы | ел | | стеналар материалы | Катлар саны | Подъездлар саны | Күпфатирлы йортның гомуми мәйданы | Биналар мәйданы | | Программаны раслау датасына КФЙда теркәлгән халык саны | Ремонт төре | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды программасы буенча капиталь ремонт бәясе | | | | | КФЙ гомуми мәйданының 1 кв. метрын капитальремонтлауның чагыштырма бәясе | КФЙ гомуми мәйданының 1 кв. метрын капитальремонтлауның иң чик бәясе | Эшләрне тәмамлауның планлы датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Эксплуатациягә кертү | Соңгы капитальремонтны төгәлләү | | | | | Барлыгы | шул исәптән гражданнар милкендәге торак урыннары | | | Барлыгы | шул исәптән: | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | РФ бюджеты | бюджет субъект бюджеты | МӨ бюджеты | милекчеләр акчалары | | | |
| | | | | | | | кв.м | кв.м | кв.м | кеше | | сум | сум | сум | сум | сум | сум\кв.м | сум\кв.м | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| **2023** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | ш.т.б. Урыссу, Альберт Шамкин ур., 49 йорт | 1993 | 1997 | җыелма-щит панельләре | 5 | 2 | 2347,40 | 2026,50 | 2026,50 | 111 | фасадны җылыту | 7 503 721,60 | 0,00 | 1 226 858,48 | 1 053 522,51 | 5 223 340,61 | 3 196,61 | 14 000,00 | 31.12.2023 |
| 2 | ш.т.б. Урыссу, Урыссу ур., 22а йорт | 1991 | 1991 | җыелма-щит | 5 | 5 | 4713,00 | 4113,57 | 4113,57 | 195 | фасадны | 12 538 | 0,00 | 2 047 715,38 | 1 760 335,91 | 8 729 953,78 | 2 660,30 | 14 000,00 | 31.12.2023 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | панельләре | | | | | | | жылыту | 005,07 | | | | | | | |
| 3 | пш.т.б. Урыссу, Тукай ур, 25 йорт | 1959 | 2011 | кирпеч | 2 | 2 | 711,60 | 653,40 | 653,40 | 24 | фасадны жылыту | 3 735 672,42 | 0,00 | 610 782,44 | 524 488,41 | 2 600 401,57 | 5 249,68 | 14 000,00 | 31.12.2023 |
| 4 | ш.т.б. Урыссу, Жуков ур., 45 йорт | 1953 | 2010 | кирпеч | 2 | 2 | 459,20 | 405,80 | 405,80 | 16 | фасадны жылыту | 3 484 415,73 | 0,00 | 569 701,97 | 489 211,97 | 2 425 501,79 | 7 588,01 | 14 000,00 | 31.12.2023 |
| 5 | Әбсәләм ав., Советская ур., 56А йорт, | 1991 | 2009 | вак блоклар, ясалма һәм табигый ташлар | 2 | 2 | 981,40 | 821,60 | 821,60 | 33 | фасадны жылыту | 3 833 199,30 | 0,00 | 626 728,09 | 537 906,67 | 2 668 564,54 | 3 905,85 | 14 000,00 | 31.12.2023 |
| 6 | ш.т.б. Урыссу, Пушкин ур., 103 йорт | 1953 | 2010 | вак блоклар, ясалма һәм табигый ташлар | 2 | 1 | 413,60 | 397,90 | 397,90 | 13 | фасадны жылыту | 2 062 211,75 | 0,00 | 337 171,62 | 289 534,53 | 1 435 505,60 | 4 986,01 | 14 000,00 | 31.12.2023 |
| | **Барлыгы:** | | | | | | **9626,20** | **8418,77** | **8418,77** | **392** | | **33 157 225,87** | **0,00** | **5 418 957,98** | **4 655 000,00** | **23 083 267,89** | | | |
| **2024** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | ш.т.б. Урыссу, Альберт Шамкин ур., 48 йорт | 1994 | 1998 | кирпеч | 3 | 3 | 1813,40 | 1680,30 | 1680,30 | 88 | ХВС, электр белән тәэминитү, су үткәрү | 2 350 000,00 | 0,00 | 500 315,00 | 429 580,00 | 1 420 105,00 | 1 295,91 | 14 000,00 | 31.12.2024 |
| 2 | ш.т.б. Урыссу, Урыссу ур., 66 йорт | 1992 | 1992 | кирпеч | 4 | 2 | 1343,50 | 1200,20 | 1200,20 | 48 | фасадны жылыту | 5 600 000,00 | 0,00 | 1 192 240,00 | 1 023 680,00 | 3 384 080,00 | 4 168,22 | 14 000,00 | 31.12.2024 |
| 3 | ш.т.б. Урыссу, Пушкин ур., 95 йорт | 1953 | 2009 | вак блоклар, ясалма һәм табигый ташлар | 2 | 2 | 798,20 | 759,00 | 759,00 | 28 | фасадны жылыту | 4 100 000,00 | 0,00 | 872 890,00 | 749 480,00 | 2 477 630,00 | 5 136,56 | 14 000,00 | 31.12.2024 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Алабакүл авылы, Үзәк ур., 1 йорт | 1978 | 2010 | кирпеч | 2 | 2 | 789,20 | 730,30 | 730,30 | 35 | фасадны жылыту | 3 707 205,57 | 0,00 | 789 352,98 | 677 680,00 | 2 240 172,59 | 4 697,42 | 14 000,00 | 31.12.2024 |
| 5 | Әбсәләм ав., Комсомольский ур., 3 йорт | 1978 | 2009 | җыелма-щит панельләре | 2 | 2 | 1359,00 | 1172,30 | 1172,30 | 51 | фасадны жылыту | 4 850 000,00 | 0,00 | 1 032 080,00 | 887 065,00 | 2 930 855,00 | 3 568,80 | 14 000,00 | 31.12.2024 |
| 6 | Әбсәләм ав., Комсомольский ур., 4 йорт | 1979 | 2010 | җыелма-щит панельләре | 2 | 2 | 1410,10 | 1178,50 | 1125,10 | 54 | фасадны жылыту | 4 850 000,00 | 0,00 | 1 032 080,00 | 887 515,00 | 2 930 405,00 | 3 439,47 | 14 000,00 | 31.12.2024 |
| | **Барлыгы:** | | | | | | **7513,40** | **6720,60** | **6667,20** | **304,00** | | **25 457 205,57** | **0,00** | **5 418 957,98** | **4 655 000,00** | **15 383 247,59** | | | |
| | | | | | | | | | **2025** | | | | | | | | | | |
| 1 | Урыссу ш.т.б., Урыссу ур., 72 йор | 1992 | 1992 | кирпеч | 4 | 2 | 1309,80 | 1142,50 | 1142,50 | 48 | фасадны жылыту | 5 500 000,00 | 0,00 | 1 001 550,00 | 860 750,00 | 3 637 700,00 | 4 199,11 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 2 | Урыссу ш.т.б., Урыссу, 24 йорт | 1968 | 1968 | кирпеч | 5 | 4 | 3244,87 | 3195,92 | 2844,12 | 129 | ХВС, электр белән тәэминитү, су үткәрү | 4 350 000,00 | 0,00 | 792 135,00 | 680 775,00 | 2 877 090,00 | 1 340,58 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 3 | ш.т.б. Урыссу, М.Җәлил ур., 6а | 1998 | 1998 | җыелма-щит панельләре | 5 | 1 | 1291,10 | 1117,30 | 1117,30 | 60 | фасадны жылыту, кровля | 6 700 000,00 | 0,00 | 1 220 123,52 | 1 046 446,50 | 4 433 429,98 | 5 189,37 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 4 | ш.т.б. Урыссу, Пушкин ур., 99 | 1968 | 2009 | вак блоклар, ясалма һәм табигый ташлар | 2 | 1 | 410,30 | 395,10 | 395,10 | 18 | фасадны жылыту | 2 750 000,00 | 0,00 | 500 775,00 | 430 375,00 | 1 818 850,00 | 6 702,41 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 5 | ш.т.б. Урыссу, Пушкин ур, 109 | 1953 | 1953 | вак блоклар, ясалма һәм табигый ташлар | 3 | 2 | 814,20 | 785,50 | 785,50 | 28 | фасадны жылыту | 5 230 000,00 | 0,00 | 952 383,00 | 818 495,00 | 3 459 122,00 | 6 423,48 | 14 000,00 | 31.12.2025 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | ш.т.б. Урыссу, Мияссаров ур., 48 | 1965 | 2002 | кирпеч | 2 | 2 | 519,90 | 459,90 | 459,90 | 20 | фасадны җылыту | 3 100 000,00 | 0,00 | 564 510,00 | 485 150,00 | 2 050 340,00 | 5 962,69 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 7 | ш.т.б. Урыссу, Жуков ур, 17 | 1949 | 2010 | агач | 1 | 1 | 100,00 | 100,00 | 100,00 | 6 | кровля | 807 849,87 | 0,00 | 147 109,46 | 126 428,50 | 534 311,91 | 8 078,50 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 8 | ш.т.б. Урыссу, Островский ур., 25 йорт | 1969 | 1986 | агач | 1 | 1 | 244,80 | 204,80 | 204,80 | 17 | кровля | 1 320 000,00 | | 240 372,00 | 206 580,00 | 873 048,00 | 5 392,16 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| | **Нибары:** | | | | | | **7934,97** | **7401,02** | **7049,22** | **326,00** | | **29 757 849,87** | **0,00** | **5 418 957,98** | **4 655 000,00** | **19 683 891,89** | | | |
| | **Барлыгы:** | | | | | | **25074,57** | **22540,39** | **22135,19** | **1022,00** | | **88 372 281,31** | **0,00** | **16 256 873,94** | **13 965 000,00** | **58 150 407,37** | | | |